# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2015 елның 30 декабре № 23

Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 елдагы Федераль законның 15 статьясы нигезендә № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында», «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 23.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 10 статьясы, Өтәшкә авыл җирлегенең 2015 елның 28 декабрендәге 21 номерлы Карарына нигезләнеп, «Җирле референдум уздыруны инициативалау турында», Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 декабрендәге 21 номерлы карары нигезендә «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. 2016 елның 06 мартына Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2016 елда Өтәшкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме»:

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Төзелеш, агымдагы һәм капиталь ремонт, эчтәлек:<br>- урам яктырту;<br>- автомобиль юллары, ишегалды | 35000 |

| | | |
|---|---|---|
| | территорияләре, кварталара юллар;<br> - су челтәрләре һәм канализацияләр. | |
| 2. | Юлларны паспортлау | 10000 |
| 3. | Янгынга каршы су белән тәэмин итү объектларын һәм чыганакларын төзү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау (пирслар, краннар, гидрантлар, ясалма сулыклар, сулыкларга керү юллары) | 15000 |

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Өтәшкә авыл җирлеге информацион стендларында: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а һәм Өтәшкә мәдәният йорты бинасында (Үзәк ур., 40а) халыкка җиткерергә.

**Өтәшкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе: Н. М. Тухтаркин**